РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Тумутукского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Тельмана, д. 62 Б, Азнакаевский район,
с.Тумутук, 423316,
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
башкарма комитеты

Тельман ур., 62 Б йорт, Азнакай районы,
Тымытык авылы, 423316
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«01»апрель 2024ел** **№ 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.07.2021 елның №22 “Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетының “Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешне кертү хакында (12.10.2021 №30 карар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 05 февралендәге 124 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитеты карар кабул итте:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.07.2021 елның №22 “Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетының “Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (12.10.2021 №30 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 10 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гариза белән "кадастр эшчәнлеге турында" Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә адреслашу объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләре яки комплексны кадастр эшләре башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

1.2. 2.3.2 пунктында «берләштерелергә мөмкин» сүзен «берләшә» сүзе белән алыштырырга.

1.3. 2.4.1 пунктында:

а) беренче абзацта «8 эш көненнән артык түгел» дигән сүзләрне «гариза килгән көннән алып 10 эш көненнән артык түгел» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

б) «регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәннән соң 3 эш көне» дигән сүзнец икенче абзацында «регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән артык түгел» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Э.Х.Гыйләҗева